
**“Укучыларыбыз - 2 гимназия горурлыгы!”**

## Филимонов Илья Александрович



Филимонов И.А. 1992 нче елның 12 октябрендә Чаллы шәһәрендә туа. 1999 нчы елда М.Вахитов исемендәге 2 гимназиягә укырга керә һәм 2009 нчы елда уңышлы тәмамлый. Иптәшләре арасында максатчан, көчле характерлы, тыныч холыклы булуы белән аерылып тора. 13 нче сәнгать мәктәбенең баян классын тәмамлый, бик матур итеп баянда уйный. Спорт белән шөгыльләнә, таэквандо буенча төрле дәрәҗәдәге ярышларда нәтиҗәләргә ирешә. 2 гимназиядә алган белем – күнекмәләр киләчәктә егеткә зур ярдәм итә.




Ул 2009 - 2014 нче елларда Россия Эчке эшләр министрлыгы каршындагы Казан юридик институтында укый һәм аны уңышлы тәмамлый.

2014-2015 нче елларда Илья Филимонов Мәскәү Кремле комендантына хезмәт күрсәтүче Президент полкында (ПП СКМК ФСО РФ) хезмәт итә. Хәзерге көндә Казан шәһәрендә Эчке эшләр идарәсендә тикшерүче булып эшли. Укучыбыз - 2 гимназия горурлыгы!



Сафта сулдан беренче Филимонов И. А.



Татарстан Республикасы Президенты Р. Н. Миңнеханов

Филимонов Ильяга истәлек сәгате тапшыра



Р. Н. Миңнеханов Президент полкында хезмәт итүче

Татарстан солдатлары арасында

Тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Харисова Э.М.